ГОСУДАРСТВЕННАЯ ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ

ул. Большая Красная, 15/9, г. Казань,420111

Зур Кызыл ур., 15/9, Казан ш., 420111

тел/факс. 8 (843) 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ 331

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

21 октябрь 2016 ел

**Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2014 елның 26 маендагы “Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вакант вазифасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) карата конкурс үткәрү турында нигезләмә раслау хакында”гы № 85 боерыгына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2014 елның 26 маендагы “Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вакант вазифасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) карата конкурс үткәрү турында нигезләмә раслау хакында”гы № 85 боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

боерык нигезенедә расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вакант вазифасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) карата конкурс үткәрү турында нигезләмәдә (алга таба – Нигезләмә):

4.4.8 пунктын түбәндәге төзәтмәсендә бәян итәргә:

“4.4.8. Конкурсның икенче этабы тест сынаулары, хосусый тармак биремнәрен әзерләү, язмача өй эшен эшләү һәм конкурс комиссиясе әгъзалары белән шәхси әңгәмә кору рәвешләрендә үткәрелә.”;

4.4.9 пунктында түбәндәге эчтәлекле кызыл юлларны өстәргә:

“Хосусый тармак биреме язмача, җавап өчен вакыт билгеләнеп башкарыла.

Язмача өй эше билгеле бер темага эссе жанрында эшләнә.”;

Нигезләмәгә карата 3 кушымтада:

“Граждан (гражданлык хезмәткәре) вакант вазифага карата квалификация таләпләренә җавап бирмәве, шулай ук гражданлык хезмәтенә

керү һәм аны үтү өчен Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәте турындагы законнарында билгеләнгән чикләмәләргә ия булуы аркасында конкурста катнашуга кертелми.”;

3 пунктны түбәндәге төзәтмәсендә бәян итәргә:

“3. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте (алга таба – гражданлык хезмәте) белеменә һәм стажына яки гражданлык хезмәте вазифаларын биләү өчен эш стажына (тәҗрибәсенә) карата квалификация таләпләре:

1) гражданлык хезмәтенең төп вазифалар төркемендәге “җитәкчеләр” категориясе өчен белгечлек, магистратура дәрәҗәсеннән түбән булмаган югары белемгә, әйдәп баручы яки өлкән төркем гражданлык хезмәте вазифаларында кимендә ике еллык гражданлык хезмәте стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә өч еллык эш стажына ия булу мәҗбүри;

2) гражданлык хезмәтенең әйдәп баручы вазифалар төркемендәге “җитәкчеләр” категориясе өчен югары белемгә, өлкән яки кече төркем гражданлык хезмәте вазифаларында кимендә бер еллык гражданлык хезмәте стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике еллык эш стажына ия булу мәҗбүри;

3) гражданлык хезмәтенең әйдәп баручы вазифалар төркемендәге “белгечләр” категориясе өчен югары белемгә, өлкән яки кече төркем гражданлык хезмәте вазифаларында кимендә бер еллык гражданлык хезмәте стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике еллык эш стажына ия булу мәҗбүри;

4) гражданлык хезмәтенең әйдәп баручы вазифалар төркемендәге “тәэмин итүче белгечләр” категориясе өчен югары белемгә, өлкән һәм кече гражданлык хезмәте вазифаларында кимендә бер еллык гражданлык хезмәте стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике еллык эш стажына ия булу мәҗбүри;

5) гражданлык хезмәтенең өлкән һәм кече вазифалар төркемендәге “тәэмин итүче белгечләр” категориясе өчен эшчәнлек юнәлешенә туры килә торган һөнәри белемгә ия булу мәҗбүри. Гражданлык хезмәтенең өлкән һәм кече вазифалар төркемендәге вазифаларны биләү өчен гражданлык хезмәте стажына яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына (тәҗрибәсенә) карата квалификация таләпләре билгеләнми.”;

Боерыкка карата 2 кушымтаны яңа эчтәлегендә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вакант вазифасын биләү (кадрлар резервына кертелү) буенча кандидатлар тарафыннан тапшырыла торган документлар һәм материаллар исемлеге

Конкурста катнашу теләген белдергән Россия Федерациясе гражданы Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә түбәндәгеләрне тапшыра:

а) шәхси гариза;

б) рәвеше Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана торган, үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета, фотоларын (2,5х3,5 зурлыгында өч фото һәм 4х6 зурлыгында ике төсле фото, тонык кәгазьдә, чатсыз, ак фонда) теркәп;

в) паспортның яки аны алмаштыра торган документның күчермәсе (тиешле документ конкурска килгәч шәхсән күрсәтелә);

г) кирәкле һөнәри белемне, квалификацияне һәм эш стажын раслый торган документлар:

хезмәт кенәгәсенең (хезмәт эшчәнлеге (хезмәт итүе) беренче башкарылган очраклардан кала) нотариаль яктан яки эш (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәсе яки гражданның хезмәт эшчәнлеген (хезмәт итүен) раслый торган башка документлар;

белем алу турында һәм квалификация турында документларның күчермәләре, шулай ук, гражданның ихтыяры буенча, өстәмә һөнәри белем алу нәтиҗәләре буенча квалификация күтәрүне яки квалификация бирелүне раслый торган документларның, фәнни дәрәҗә, фәнни исем бирелүне раслый торган документларның нотариаль яктан яки эш (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәләре;

д) гражданның гражданлык хезмәтенә керүе һәм аны үтүе өчен комачау итә торган чирләре булмавы турында документ;

е) 2004 елның 27 июлендәге “Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәте турында” № 79-ФЗ Федераль законда, башка федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында яки Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында каралган бүтән документлар.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә, анда гражданлык хезмәте вазифасын биләгән, конкурста катнашырга теләк белдергән гражданлык хезмәткәре гаризаны Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе башлыгы исеменә тапшыра.

Башка дәүләт органында конкурста катнашу теләген белдергән гражданлык хезмәткәре шул дәүләт органына эшкә алучының вәкиле исеменә гариза һәм үз кулы белән тутырылган, имзаланган һәм гражданлык хезмәткәре гражданлык хезмәте вазифасын били торган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган анкетаны фотоларын теркәп тапшыра. Анкетаның рәвеше Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана.

Документлар Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендәге рәсми сайтында аларны кабул итү турында игълан урнаштырылган көннән соң 21 көн эчендә Казан ш., Зур Кызыл ур., 15/9 й. адресы буенча кабул ителә, факс (843)236-93-66, рәсми сайт: gji.tatarstan.ru.

Документларны әһәмияткә лаек сәбәпләрсез үз вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә тапшырмау яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданнан аларны кабул итеп алудан баш тартуга нигез булып тора.

Документларны әһәмияткә лаек сәбәпләр аркасында үз вакытында тапшырмаганда, аларны тулы күләмдә тапшырмаганда яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшырганда Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе башлыгы аларны кабул итү вакытын күчерергә хокуклы.”.

2. Кадрлар бүлеге башлыгына (И.Н.Никитина) кызыксынган барлык затларны шушы боерык белән таныштырырга.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Башлык С.А.Крайнов